КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2021 ел, 11 февраль

г.Казань

№ 70

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 - 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 03 февраль, 72 нче карары белән расланган 2020 - 2024 елларда Шәхси медицина оешмаларына - шәхси медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектында катнашу өчен конкурс сайлап алу җиңүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 - 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү

буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 03 февраль, 72 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 705 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2020 - 2024 елларда Шәхси медицина оешмаларына - шәхси медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектында катнашу өчен конкурс сайлап алу җиңүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

«а» пунктчасында «, хирургия һәм эндокринология» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» һәм «в» пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) пилот проекты кысаларында хезмәт күрсәтү планлаштырыла торган хосусый медицина оешмасында табиб-терапевтның яисә гомуми табиб практикасы табибының (гаилә медицинасының) кимендә бер тулы ставкасы булу һәм 65 яшьлек һәм өлкәнрәк яшьтәге 60 затка шәфкать туташы һәм (яисә) фельдшерның ике тулы ставкалары булу;»;

5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Пилот проектында катнашу өчен хосусый медицина оешмасы вәкаләтле органга вәкаләтле орган билгеләгән срокта пилот проектында катнашуга гариза җибәрә. Күрсәтелгән мәгълүмат гаризалар кабул ителә башлаганчы кимендә биш эш көне кала вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

6 пунктның «а» пунктчасының җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

18 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча» сүзләрен «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин